УПРАВЛЕНИЕ
ПО ОХРАНЕ И
ИСПОЛЬЗОВАНИЮ
ОБЪЕКТОВ
ЖИВОТНОГО МИРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
ҺӘМ АЛАРДАН
ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

---

**Приказ** **Боерык**

«22» июлендәге 2015 елның г. Казань № 94-од

Татарстан Республикасы Хайваннар
дөньясы объектларын саклау һәм
алардан файдалану идарәсенә кергән
гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау
тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясын, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 23 статьясын тормышка ашыру һәм Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә гражданнарның мөрәҗәгать итүенә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында боерам :

1. Әлеге Боерыкка бирелгән кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.
2. Эшне оештыруны, мәгълүмат белән тәэмин итүне һәм Тәртипнең үтәлешен тикшереп торуны баш белгеч Р.Г. Гайнановка тапшырырга.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе башлыгы урынбасары Ю.Б. Матвеевка йөкләргә.

Идарә башлыгы Ф.С.БАТКОВ

Татарстан Республикасы
Хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм алардан файдалану
идарәсенең 22.07.2015 ел.
94-од номерлы боерыгы
белән расланган

**Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе (алга таба - Тәртип) 2006 елның 2 маендагы N 59-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Федераль законның 14 статьясын һәм “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

1.2. Нигезләмә, гражданнар мөрәҗәгатьләренә йогынты ясаучы сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатында, гражданнарның Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенә (алга таба - Идарә) кергән мөрәҗәгатьләренә анализ ясауны уздыру критерийларын һәм шартларын билгели.

II. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе

2.1. Идарәгә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ, ярты ел һәм үткән ел йомгаклары буенча җаваплы белгеч тарафыннан ясала.

2.1. Идарәгә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау, җаваплы белгеч тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының "Электрон Хөкүмәт" электрон документлар әйләнеше Бердәм ведомствоара системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

2.2. Идарәгә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау анализы, хисап чорыннан соң килә торган айның 22 нче числосыннан да соңга калмыйча Идарәнең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә урнаштырыла.

2.3. Бүлек белгече тарафыннан үткәрелгән Идарәгә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча, Идарәдә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында аналитик белешмә (мәгълүмат) рәсмиләштерелә.

2.4. Аналитик белешмәдә (мәгълүматта) түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш

(хисап чоры кысаларында):

кергән, күчерелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны;

электрон документ рәвешендә гражданнардан кергән, кабат адресланган һәм каралган мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре, даталары һәм сәгатьләре турында;

шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турында;

гражданнарны шәхси кабул итү һәм урынга чыгып кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;

мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында;

мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар турындагы (булган очракта) мәгълүмат.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Әлеге Тәртипкә кертелә торган барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Идарә башлыгы боерыгы белән раслана.